# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында ветеринария эше турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында ветеринария эше турында" 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 10 (8); 2003, № 5; 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлек исемендә "Җирле үзидарәнең ветеринария оешмалары." сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 5 статьяда:

а) 1 өлештә "йогышлы булмаган массакүләм" сүзләрен "башка" сүзенә алмаштырырга;

б) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы җитәкчесе законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вазыйфасына билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә.";

3) 6 статьяда:

а) 5 пунктта "йогышлы булмаган" сүзләрен "башка" сүзенә алмаштырырга;

б) 6 пунктта "һәм массакүләм йогышлы булмаган" сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7 статья. **Дәүләт региональ ветеринария күзәтчелеге**

1. Татарстан Республикасында дәүләт региональ ветеринария күзәтчелеген Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үз компетенциясе нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга дәүләт региональ ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруга, аларны тикшерүне оештыруга һәм үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.";

5) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнары вазыйфаи затларының хокуклары**

Дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнарының дәүләт ветеринария инспекторлары булып торучы вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

оешмаларга, алар тарафыннан Россия Федерациясе законнарының үтәлешен тикшерү, эпизоотиягә каршы һәм башка ветеринария чараларын үткәрү һәм гамәлдәге ветеринария кагыйдәләрен үтәү максатларында, ветеринария турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тоткарлыксыз керергә һәм аларны тикшерергә;

эпизоотиягә каршы һәм башка чаралар үткәрү турында, ветеринария турында Россия Федерациясе законнарын бозуларны бетерү хакында оешмаларга һәм гражданнарга таләпләр куярга, шулай ук әлеге таләпләрнең үтәлешен тикшереп торырга;

терлекләрнең йогышлы авырулары һәм ветеринария-санитария ягыннан зарарсыз булмаган терлекчелек продуктлары барлыкка килүнең һәм таралуның сәбәпләрен, шартларын билгеләргә;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.";

6) 11 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 14 статьяның 1 өлешендә татарча текст үзгәрми;

8) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"17 статья. **Терлекләрнең йогышлы авырулары чыганаклары барлыкка килү очракларында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бурычлары**

1. Татарстан Республикасы территориясендә терлекләрнең йогышлы авырулары барлыкка килү һәм таралу куркынычы килеп туган очракта, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма

хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органының тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җитәкчесе тәкъдиме нигезендә чикләү гамәлләре (карантин) билгеләнә.

2. Терлекләрнең йогышлы авырулары, аеруча куркыныч авырулардан тыш, барлыкка килү һәм таралу куркынычы килеп туган очракта, чикләү гамәлләре (карантин) билгеләнү турында карар Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органының тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җитәкчесе тарафыннан кабул ителергә мөмкин.

3. Терлекләрнең йогышлы авырулары чыганаклары таралуны кисәтү һәм юкка чыгару буенча юридик һәм физик затлар эшчәнлекләренә оператив җитәкчелек итү һәм әлеге эшчәнлекне координацияләү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы билгеләнгән тәртиптә махсус комиссияләр төзи.

4. Татарстан Республикасы территориясендә чикләү гамәлләре (карантин) билгеләнү очрагында, Татарстан Республикасы Президенты терлекләрнең йогышлы авырулары чыганакларын юк итү буенча Россия Федерациясе ветеринария законнарында каралган махсус чараларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итә.

5. Дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар терлекчелек калдыкларын җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыралар.";

9) 18 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"– терлекләр авыруларын кисәтүне һәм терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария ягыннан зарарсызлыгын тәэмин итүче хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашырырга, терлекчелек биналарын һәм терлек азыкларын саклау һәм терлекчелек продуктларын эшкәртү корылмаларын тиешле халәттә тотарга, терлекчелек калдыклары белән әйләнә-тирә мохитнең пычрануына юл куймаска.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 82-ТРЗ